Бөек Ватан сугышы ветераны **Бәширов Шәйхулла абый** истәлекләре (Истәлекләр белән аның туганы таныштырды. Ул 2016 нчы елда бакыйлыкка күчте). Ул 1924 нче елда туган. Бөек Ватан сугышында катнашкан. Авылда колхоз председателе булып эшләгән.



Ул пионер булуы турында менә нәрсәләр язып калдырган:

“”...1933 елда безне Абзалова Халимә дигән укытучы өченче класста укыта иде. Беркөнне ул совет мәктәпләрендә укучы дистә меңләгән балаларның пионер отрядлары сафларында тәрбияләнүләрен, пионерларның кемнәр булуын, пионер оешмасының структурасын сөйләп аңлатты. Пионерларның аерымлык билгеләре, атрибутлары белән таныштырды һәм безнең дә пионер була алуыбыз турында әйтте. Шул көннән башлап без пионерга керү турында хыяллана башладык. Ул, пионер булу өчен укучы һәр эштә һәм һәр җирдә үзен башкаларга үрнәк булырлык итеп тотарга, тырышып укырга кирәклеген әйтә килде.

Пионерларның тантаналы вәгъдәләрен һәм пионерлар маршын өйрәтте. Озак та үтмәде, без пионерларның тантаналы вәгъдәсен укып пионер булдык. Муеннарыбызгакызыл галстук тактылар. Ул кызыл материядән эшләнгән иде. Шул минутта Халимә апабыз безне пионер булуыбыз белән котлады. Халимә апаның муенына да кызыл галстук тагылган иде.

Шул көннән башлап бездә укуга һәм файдалы хезмәткә дәрт кабынды.”

Менә алар – авылыбызның беренче пионерлары:

1.Бәширов Шәйхулла
2.Вафин Сәгыйть
3.Исламов Касыйм
4.Кузьмин Иван
5.Билалова Галия.
6.Яруллина Әзекәр
7.Х. Шакир

8.Вәлиев Вагиз
9.Вәлиева Галия
10.Ахметова Галия
11.Шәйхетдинов Зыятдин
12.Вәлиев Азат
13.Махмутов Мансур
14.Махмутов Сабир

Пионерлар кызыл галстук, ак күлмәк киеп башка укучылардан аерылып торалар, алар акрынлап башка укучыларны да үзләренә ияртәләр. Пионер оешмасы мәктәпнең җитәкче органына әйләнә.Бу укучылар мәктәп тормышында гына түгел, авыл халкы арасында да иң актив, иң тырыш, тәртипле укучылар булалар. Бу чорда бара торган үзгәрешләрдә үзләреннән булдыра алган кадәр зур өлеш кертәләр: халыкны укырга-язарга өйрәтү, ачыккан гаиләләргә ярдәм оештыру, ялгыз карчыкларга ярдәм итү – бу әле беренче пионерлар эшләгән эшләрнең кайберләре генә.

Урманасты Шынталысы